| | |
|---|---|
| **СОВЕТ СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ-ТӘРБИТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

РЕШЕНИЕ КАРАР

16.09. 2019 ел ИСКЕ ТӘРБИТ АВЫЛЫ № 18

ИСКЕ ТӘРБИТ авыл җирлегендә
Җирле референдум үткәрү
инициативасы турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 нче Федераль законның 56 нчы маддәсе, «Россия Федерациясе гражданнарының төп сайлау хокуклары гарантияләре һәм референдумда катнашу хокукы турында»гы 2002 елның 12 июнендәге 67 нче Федераль законның 15 нче маддәсе, Татарстан Республикасының «Җирле референдум турында»гы 2004 елның елның 25 мартындагы 23 нче законынның 12 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы ИСКЕ ТӘРБИТ авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставының 11 нче маддәсе нигезендә ИСКЕ ТӘРБИТ авыл җирлеге Советы КАРАР кабул итте:

1. ИСКЕ ТӘРБИТ авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә ИСКЕ ТӘРБИТ авыл җирлегендә референдум үткәрү турындагы инициативаны түбәндәге сорауларны кертеп үткәрергә:

«Сез, 2019 елда ИСКЕ ТӘРБИТ авыл җирлегендә 18 яше тулып, референдумда катнашу хокукы булган һәр кешедән үзара салым акчасының бер тапкыр 500 (биш йөз) сум күләмендә түләнүе белән килешәсезме». Үзара салымнан кергән керем түбәндәге юнәлешләрдә тотыла:

а) **авыл җирлеге территориясен төзекләнләндерү**:

- җирлектәге торак пунктлардагы санкцияләнгән һәм санкцияләнмәгән чүплекләр территорияләрен чистарту;
- җирлектәге торак пунктларындагы күперләрне төзекләндерү һәм моның өчен материаллар сатып алу;

б) **авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:**

- суүткәргеч челтәрен төзекләндерү һәм моның өчен материаллар сатып алу;

в) **авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:**

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

г) **ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру, җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тоту:**

- зиратларны тезекләндерү һәм җирләү урыннарын тиешле тәртиптә чистартып тоту өчен материаллар сатып алу.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматенең рәсми порталында, мәгълүмат стендларында һәм Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмәт-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://styaberdin-kaybici.tatarstan.ru .
3. Карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен үзем өскә калдырам.

Авыл җирлеге җитәкчесе В.Г.Тимофеев